**Республика Татарстан**
**Старо-Имянское сельское**
**поселение Сармановского**
**муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль**
**районы Иске Имән**
**авыл җирлеге**

**КАРАР**
**24.09.2018**

**КАРАР**
**№ 97**

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Иске Имән авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Иске Имән авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, «Референдум уздыруны инициацияләү турында» 2018 елның 17 сентябрендәге 95 номерлы карары нигезендә, Иске Имән авыл җирлеге Советы карар итте:

Иске Имән авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча 2018 елның 18 ноябренә җирле референдум билгеләргә.

1. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

"2019 елда үзара салым чараларын Иске Имән авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 200 сум күләмендә кертүгә сез килешәсезме, моңа I төркем инвалидларыннан, ашыгыч хәрби хезмәт итүче гранданнардан тыш һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән дә килешәсезме:

1)Ял вакытын оештыру һәм җирлектә яшәүчеләрне мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру:

- Иске Имән һәм Сарысаз-Тәкемән авылларында “Сабантуй”, “Өлкәннәр көне”, “Яңа ел” бәйрәмнәрен уздыру өчен бүләкләр алу;

- Иске Имән һәм Сарысаз-Тәкермән авылларында бәйрәм чаралары үткәрү өчен музыка апаратурасы алу;

2) Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен тикшереп тору, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Иске Имән һәм Сарысаз-Тәкермән авылларында яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру);

- Иске Имән һәм Сарысаз-Тәкермән авылларындагы памятниклар өчен краска сатып алу;

- Иске Имән һәм Сарысаз-Тәкермән авылларындагы ял итү урыннары төзү өчен төзелеше материаллары сатып алу;

- Беларусь-МТЗ 320.4-Ч махсус техникасын тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, йөртүчегә түләү);

- Торак пунктларда көнкүреш калдыклары һәм чүп-чар җыю урыннарын җыештыру.

3)Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:

-Сарсысаз-Тәкермән авылы өсен мотопомпа сатып алу;

-Сарысаз-Тәкермән авылы өчен янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру.

ӘЙЕ ЮК

2. Мәгълүмат стендларында һәм Иске Имән авыл җирлегенең рәсми сайтында кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә әлеге карарны игълан итәргә.

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге
Советы рәисе Р.Ә.Исламова